КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 2 август

г.Казань

№ 752

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гомуми файдаланудагы төбәк әһәмиятенә яки муниципальара әһәмияткә ия булган автомобиль юллары буйлап авыр йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары китерә торган зыян күләмен билгеләү турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер норматив хокук актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 2 сентябрь, 699 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап хәрәкәт иткәндә авыр йөкле транспорт чаралары китерә торган зыян күләме күрсәткечләренә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гомуми файдаланудагы төбәк әһәмиятенә яки муниципальара әһәмияткә ия булган автомобиль юллары буйлап авыр йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары китерә торган зыян күләмен билгеләү турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер норматив хокук актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 2 сентябрь, 699 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 16 март, 192 нче; 2015 ел, 20 июнь, 445 нче; 2018 ел, 15 декабрь, 1147 нче, 2020 ел, 6 июль, 552 нче, 2022 ел, 1 апрель, 307 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасында төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап хәрәкәт иткәндә авыр йөкле транспорт чаралары китерә торган зыян күләме күрсәткечләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

искәрмәдә:

беренче абзацта «дәүләт контрактлары» сүзләреннән соң «һәм концессия килешүләре» сүзләрен өстәргә;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы төбәк яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап авыр йөк ташыганда сәнәгать өлкәсендә Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән һәм эшчәнлек алып баручы Россия икътисадының система барлыкка китерүче оешмалары исемлегенә керүче оешмаларныкы, шулай ук мондый система барлыкка китерүче оешмалар яисә аларның бүлендек предприятиеләре белән төзелгән шартнамәләр (килешүләр, контрактлар) буенча ягулык, битум һәм нефть ташуны гамәлгә ашыручы оешмаларныкы булган транспорт чаралары китерә торган зарар күләме (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елда Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтенә вакытлыча чикләүләр кертү турында» карары нигезендә хәрәкәтне вакытлыча чикләү кертү чорында иң чик мөмкин булган күчәр йөкләнешенең әһәмияте артканда) хәрәкәтне вакытлыча чикләү керткәндә кулланыла торган 2 нче таблицада билгеләнгән күрсәткечнең 0,3 енә тигез.»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Мәскәү - Түбән Новгород - Казан» тизйөрешле автомобиль юлы, 7 этап 586 км - 663 км, Чуваш Республикасы, Татарстан Республикасы (А-151 «Цивильск - Ульяновск» автомобиль юлы белән кисешкәннән алып Р-241 «Казан - Буа - Ульяновск» автомобиль юлы белән кисешкәнгә кадәр), «Төзелә торган тизйөрешле «Мәскәү - Түбән Новгород - Казан» автомобиль юлы, 8 этап 663 км - 729 км Идел елгасы аша күпер белән, Татарстан Республикасы (Р-241 «Казан - Буа - Ульяновск» автомобиль юлы белән кисешкәннән алып «Саескан Тауы - Шәле» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлы белән кисешкәнгә кадәр)», «М-7 «Идел» Түбән Кама һәм Чаллы шәһәрләрен урап узу участогында Мәскәү - Владимир - Түбән Новгород - Казан - Уфа автомобиль юлы төзелеше, Татарстан Республикасы» объектларын проектлау һәм төзү эшләре комплексын үтәүгә шартнамәләр кысаларында эшләр башкару (хезмәтләр күрсәтү) өчен шартнамәләр нигезендә подрядчылар, башкаручылар, тәэмин итүчеләр һәм аларның субподряд оешмалары тарафыннан файдаланыла торган һәм җәлеп ителә торган транспорт чаралары (иң чик мөмкин булган массаның һәм иң чик мөмкин булган күчәр йөкләнешенең әһәмиятен арттырганда) Татарстан Республикасы төбәк яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап авыр йөк ташыганда китерә торган зыян күләме нольгә тигез.».

2. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

бу карарның 1 пунктындагы бишенче абзацының гамәле 2022 елның 1 апреленнән 30 апрелена кадәр барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла;

әлеге карарның 1 пунктындагы җиденче абзац 2024 елның 30 июненә кадәр гамәлдә була.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин